Республика Татарстан
Рангазарское сельское поселение
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районынын Рангазар авыл
жирлеге

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

07.11. 2024 г.

№ 2

Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рангазар торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына нигезлэнеп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге башлыгы карар кылды:

1. 2025 елның 19 ноябрендә 14.00 сәгатькә Рангазар авылы мәдәният йорты бинасында, ТР, Сарман муниципаль районы, Рангазар авылы, Совет урамы, 48 йорт адресы буенча урнашкан, Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Рангазар авылында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Рангазар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2026 елда 10000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1) Рангазар авыл зираты территориясен киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2) Беларус-320.4 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

3) Рангазар авылында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ;

4) Рангазар авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

5) Рангазар торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

6) Рангазар авылында Сабантуй территориясен төзекләндерү;

7) Рангазар торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр өчен шартнамә буенча түләү).

"РИЗА" "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны Рангазар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге Советы рәисе Р.Н.Кыямов